**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.58

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
422870, ТР Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,58

Телефон: (84346) 20-0-26, 21-0-48, факс: (84346) 21-7-57. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: alkeevskiy.tatarstan.ru.

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Базарлы Матак авылы

2022 елның 16 июне 114№

Әлки муниципаль районы Советының 2014 елның 14 ноябрендәге «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук «Әлки муниципаль районы» берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау турында» 92 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2022 елның 1 апрелендәге «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 97-ТРЗ номерлы Федераль законны, 2020 елның 26 декабрендәге «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Әлки муниципаль районы Советының 2014 елның 14 ноябрендәге «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук «Әлки муниципаль районы» берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәне раслау турында» 92 номерлы карарына (2020.05.06. 313№, 2015.18.12, 22№, 2021.29.07, 63№ карарлар ред.)түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктның «в» пунктчасында «акцияләр» сүзен төшереп калдырырга;
13 пунктта «акцияләр» сүзен төшереп калдырырга;

13 пунктта «оешмалар» сүзеннән соң «цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әлки муниципаль районы Советының Законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль районы Башлыгы: А. Ф. Никошин